**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ**
**ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ**
**ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И**
**КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,**
**АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ**
**И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ**
**ЭТИЛ СПИРТЫ һ□М АЛКОГОЛЬЛЕ**
**ПРОДУКЦИЯ □ИТЕШТЕРҮНЕ,**
**□ЙЛ□НЕШТ□ ЙӐРТҮНЕ,**
**СЫЙФАТЫН Д□ҮЛ□Т ТИКШЕРҮЕН**
**Т□ЭМИН ИТҮ һ□М КУЛЛАНУЧЫЛАР**
**ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА**
**Д□ҮЛ□Т ИНСПЕКЦИЯСЕ**
(Татарстан Республикасы д□үл□т алкоголь инспекциясе)

---

# БОЕРЫК

_27.01.2017___ № _12 – 07/4_____

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 01.02.2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16.01.2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14.03.2011 ел, №УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре” 11.12.2015 ел, №УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 22.04.2015 ел, №12-07/15 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Кадрлар сәясәте һәм
хокук бүлеге начальнигы ________________/ А.Н.Семенова/_________________

Административ һәм
суд практикасы бүлеге начальнигы ___________ Б.Г. Эйдинов/__________________

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 27.01.2017, № 12-07/4 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар составына кертү) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составын, эшләү срокларын һәм тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар составына кертү) конкурс үткәрү методикасын билгели.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар составына кертү) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтендә эшләвенә бертигез мөмкинлекле конституцион хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел, №79-ФЗ Федераль законның 22 статьясы (алга таба - №79-ФЗ Федераль закон), “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 01.02.2005 ел, №112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16.01.2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14.03.2011 ел, №УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре” 11.12.2015 ел, №УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәүләти гражданлык хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен аларның билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс, Федераль закон нигезендә конкурс буенча билгеләнелә торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы

булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе (алга таба – җитәкче) карары белән игълан ителә.

1.4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кадрлар резервына кертүгә конкурсны, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен белгечләргә ихтимал ихтыяҗын еллык бәяләү нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе ия булган кадрлар резервы буенча, кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге оештыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертүгә конкурс, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең конкурс комиссиясе тарафыннан, бу Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

1.5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс үткәрелми:

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” гражданлык хезмәте категорияләренең вәкаләтләре билгеле бер вакытка билгеләнә торган вазыйфасына билгеләнгәндә;

- вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

- Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

- конкурс нигезендә формалаштырылган кадрлар резервындагы дәүләт хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт хезмәтенең вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

- җитәкчесе карары нигезендә, гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керә торган дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

- конкурс буенча, сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының дәүләти гражданлык хезмәтендә эшләве өчен бертигез мөмкинлекләренә конституцион хокукын, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

- федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларында билгеләнгән тиешле таләпләргә туры килеп, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саныннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң кулай кандидатларны сайлап алу;

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервын булдыру.

1.8. Конкурс үткәрүдә хәл ителә торган бурычлар:

- барлык кандидатларга конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәүдә бертигез шартлар тудыру;

- кандидатларны объектив, һөнәри яктан әһәмиятле критерийләр нигезендә бәяләү;

- конкурста катнашучылар арасыннан конкурслар процедурасы барышында объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертү)таләпләренә туры килердәй затларны билгеләү.

## II.Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргәндә, җитәкче боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2.Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә комиссия рәисе җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе югында аның бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, делолар булдыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына җитәкчесе һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегеннән, административ һәм суд практикасы бүлегеннән) һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрә торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез экспертлар-белгечләр сыйфатында, экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә, җитәкче запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган фәнни, мәгариф оешмалар һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының ким дигәндә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып формалаштырыла.

2.6.Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгу ихтималын булдырмастай итеп формалаштырыла.

2.7.Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат дәгъва кылганда үткәрелә һәм анда конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының ким дигәндә өчтән ике өлеше катнашса, узды, дип исәпләнелә. Гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырыш үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

2.9.Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

2.10.Конкурс комиссиясе әгъзалары кабул итә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, беркетмәгә утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясе әгъзалары имза сала.

2.11.Конкурс үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры оештыру һәм тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге хәл итә.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) карата тиешле таләпләргә туры килүче, бу Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны бу Нигеләмәнең 3.7 пунктында күздә тотылган срокта тапшыручы Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

3.2. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфаларын) биләү өчен тиешле квалификация таләпләренә туры

килмәвенә һәм Федераль законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

Кандидатларга Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) карата таләпләр дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшыра:

- шәхсән гариза (бу Нигеләмәгә №1 кушымта);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, № 667–р,карары белән расланган формада үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәтләре (4 х 6 см) белән;

- паспорт яки аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);
- кирәкле һөнәри белемгә ия булуны, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар;
- нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт эшчәнлегенә (хезмәт итү) тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш) яки гражданинның хезмәт эшчәнлеген (хезмәт итү)раслаган башка документлар;
- нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган, гражданинның белеме һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның үз теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яки квалификация бирүне раслаган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре;
- гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә яки аны үтүенә комачаулык тудырырдай авырудан интекмәве турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14 декабрь, 2009 ел, № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у учет формасы);
- Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә күздә тотылган башка документлар.

3.5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәте вазыйфасын биләп, шунда үткәрелә торган конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре җитәкче исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләп, конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә шәхсән гариза һәм үз кулы белән тутырып, имзаланган һәм үзе гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәтендә расланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел,

№667-р боерыгы белән расланган формада анкета, фотосурәтләре (4 х 6 см) белән.

3.6. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка сер булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган очракта, гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән, аңа карата мондый мәгълүматлар беләү эшләү мөмкинлеге бирү процедурасы үткәрелә.

Гражданин тарафыннан җитәкче исеменә тапшырылган документларның дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш.

3.7.Кандидатлар конкурста катнашу өчен документларын Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасына конкурс үткәрү турында мәгълүмати хәбәрләр урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә тапшыра.

3.8. Документларны вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итеп алудан баш тартуга нигез булып тора.

Документлар нигезле сәбәпләр белән тулы күләмендә вакытында тапшырылмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда җитәкче аларны кабул итү срокларын кичектерергә мөмкин.

## IV. Конкурс үткәрү методикасы

4.1. Конкурс үткәрелгәндә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралар кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурс игълан ителгән вазыйфаларның төркемнәренә һәм категорияләренә бәйле рәвештә конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин.

4.3 .Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үткәрү нигезендә хәл ителә.

4.4.Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1.Конкурсның беренче этабында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге оештыра:

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт

хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасына конкурс үткәрү турында мәгълүматлар әзерләп урнаштыруны, бу мәгълүматлар үз эченә ала: гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) атамасын, бу вазыйфаны биләү өчен куела торган таләпләр, гражданлык хезмәтен үтәү шартлары, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар һәм материаллар исемлеге, әлеге документларны кабул итү срогы, конкурсны үткәрүнең күздә тотылган вакыты, урыны һәм тәртибен, башка мәгълүмати материалларны;

- кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерүне;

- гражданинның (гражданлык хезмәткәре) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне (һөнәри белеме дәрәҗәсен, гражданлык хезмәте (башка төрләрдәге гражданлык хезмәте) стажын яки белгечлек буенча эш (тәҗрибә) стажын, әзерлеге юнәлешен, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен).

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулык тудырырдай хәлләр билгеләнгән очракта гражданинга кадрлар сәясәте һәм коорупциягә каршы көрәш бүлеге тарафыннан конкурска кертүдән баш тарту сәбәпләре турында язмача хәбәр ителә.

4.4.3. Конкурска кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъвачы бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.4.4. Конкурсның беренче этабын төгәлләүнең шарты булып Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) билгеләнгән тиешле таләпләргә туры килгән кимендә ике кандидатның булуы тора (бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә).

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага карата квалификация таләпләрен канәгатьләндерердәй нибары бер кандидат кына булганда, конкурс, узмады, дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның тиешле санда булмавы сәбәпле конкурсның, узмады, дип танылуы турында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы төгәлләнгәннән соң җитәкче конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул итә.

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга күп дигәндә 15 көн кала конкурста катнашуга кертелгән кандидатларга аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында хәл ителә:

- конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү.

4.4.7. Конкурс комиссиясе конкурс үткәргәндә белеме, гражданлык хезмәтен яки башка дәүләт хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген хәл итү турында документлар, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган тестлар һәм башка конкурс процедуралары уздыру нигезендә кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяли, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тестлар уздыру, реферат язу, практик биремнәр үтәү, индивидуаль әңгәмә нигезендә.

4.4.8. Кандидатларга тест сынаулары электрон рәвештә үткәрелә. Конкурс комиссиясе кандидатларга тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителгән саны 25 проценттан артмаска тиеш.

Сораулар исемлеге белән җиңел генә танышу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә, һәм ул конкурста катнашучыларның түбәндәге белемнәрен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

– Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе;

– федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары;

– дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары;

– Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе турында нигезләмә;

– гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасының вазыйфаи регламенты;

– структур подразделениенең эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив-хокукый актлар буенча.

Кандидатларга тест биремнәренә җаваплар әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

4.4.9. Реферат язу өчен кандидатлар дәгъва кыла торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең дәүләт хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәүгә бәйле сораулар куллану тәкъдим ителә. Рефератлар темалары конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Кандидатлар бер үк темага реферат яза һәм аларга рефератны әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

Конкурс комиссиясе рефератларны материалның сыйфаты һәм бәян итүнең тирәнлеге, мәсьәләне ачуның тулылыгы буенча бәяли. Рефератның

нигезләмәләренең ниндидер яңалык һәм фәнни әһәмияте белән аерылып торуы игътибарга алына.

4.4.10. Кандидатларга бер үк төрле практик биремнәр һәм аларга җавап әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

4.4.11. Кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) ия булган структур подразделение җитәкчесе үткәрелгән тест, рефератны бәяләү һәм индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча һәр кандидатка бәяләмә әзерли.

4.4.12.Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) дәгъва кылучы кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 11.01.2016 ел, №1 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә хәл ителә.

4.4.13. Тест узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмәләрне конкурс комиссиясе әгъзалары үткәрә.

Индивидуаль әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелгән сорауларга телдән җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе, гражданлык хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфаның вазыйфаи регламентының башка нигезләмәләреннән, шулай ук бу Нигезләмәдә һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Конкурска йомгак ясауга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) биләүгә кандидат турында карар кабул итүгә нигезләр булып кандидатлар туплаган тавышлар саны, кандидатлар вакантлы вазыйфасына дәгъва кыла торган структур подразделение җитәкчесе фикере тора.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) буенча квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү яки яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертү хакында карар кабул итүгә хокуклы.

4.8. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчене гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында җитәкче карары чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык

хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерында карар кабул итүгә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән, гражданлык хезмәтенең шушы вакантлы вазыйфасы төркемендәге гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен, кандидатны кадрлар резервына кертү турында җитәкче боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданин) – конкурс җиңүчесен кадрлар резервына кертү җитәкче боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс төгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә язмача рәвештә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе рәсми сайтына һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырыла.

4.10. Кандидат Россия Федерациясе законы нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять белдерүгә хокуклы.

4.11. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язмача гаризалары буенча үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге срок чыкканчы, документлар Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнарны (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торакны наймга алып тору, яшәү, элемтә чараларыннан һ.б. файдалану) кандидатлар үз средстволары хисабына күтәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе җитәкчесенә

________________________________

( фамилиясе, исеме атасының исеме)

________________________________________дән

(мөрәҗәгать итүченең фам,, исеме, атасының исеме)

________________________________________

гариза тапшыру вакытына

________________________________________

яшәү урыны: эш урыны, вазыйфасы)

________________________________________

(мобиль телефоны, эл. почтасы)

гариза

Мине Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү)

__________________________________________________________________

(вазыйфа һәм подразделение атамасы)

__________________________________________________________________

конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм.

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16.01.2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 01.02.2005 ел, №112 Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмә, шулай ук вакантлы вазыйфага карата куела торган квалификация таләпләре белән таныштым. “Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, №152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Конкурс үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail аша яки күрсәтелгән мобиль телефон номеры аша хәбәр итүгә ризалык бирәм.

Гаризага кушып бирәм:

__________________________________________________________________

(кушып бирелә торган документларны санап чыгарга)

“___” ______20__ ел ________________ ________________

(имза) (тулы имза)

Кадрлар сәясәте һәм
хокук бүлеге начальнигы _______________/ А.Н.Семенова/________________

Административ һәм
суд практикасы бүлеге начальнигы __________ Б.Г. Эйдинов/_________________